
***Бергәләп өйрәник***



# ***Өлкәннәргә хөрмәт***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(4-5 яшь)***

## Мәкальләр

Картлар сүзен капчыкка сал, яшьләрнекен янчыкка сал.
Олының сүзен оекка кыстыр.
Картлар сүзен кар басмас.
Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.

### *Җырлар, такмаклар, мавыктыргычлар, эндәшләр*

Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама.
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама.
*Әй чулпысы, чулпысы,
Бигрәк матур тәңкәсе.
Аккош микән, былбыл микән
Моны тапкан әнкәсе.

### *Шигырьләр*

### *Дәү әнигә кучтәнәч*

Тутырдык без тартмага
Өрек, йөзем, алманы,
Салдык чәй дә, конфет та
Буш урыннар калмады.
Әй сөенер дәү әни,
Килеп төшкәч кучтәнәч.
Кызык булыр ул аңа,
Алдан белеп көтмәгәч.
Шәүкәт Галиев

### Хәрәкәтле уеннар
### Төлке һәм куяннар

Идәнгә зур түгәрәк сызыла. Ул — «куян балаларының оясы». Бер читтә «төлке» утыра. Балалар ояларыннан чыгып сикерәләр, уйныйлар, бииләр. Тәрбияче: «Төлке килә!» — диюгә, балалар ояларына йөгерәләр. «Төлке» аларны куа. Уен шулай дәвам итә.

### Кечкенә туплар

Балалар, түгәрәк ясап, урындыкларда утырып торалар.
Рәттән утырган 2 балага тәрбияче берәр кечкенә туп бирә. Бер
бала тупны уң якка, икенчесе сул якка җибәрә (балалар туплар-
ны бер-берләренә бирәләр). Ике туп «очрашкач», туплы балалар икесе ике якка йөгереп китәләр. Калган балалар бу вакытта «йөгердек, йөгердек» дип кабатлыйлар, кулларын чәбәклиләр. Ике бала, кара-каршы очрашкач, тупларын тәрбиячегә тапшыралар. Ул аларны башка балаларга бирә һәм уен дәвам итә.

### «Бабай һәм оныклар».

Бер бала – бабай, калганнары – оныклар; бабай өйдә уты- ра, ә оныклар өйдән читтәрәк нәрсә эшләячәкләре турында сөйләшәләр. Мәсәлән: бакчада җир казыдык, оекбаш бәйләдек, кер юдык һ.б. Аннары бабай янына киләләр, бабай алардан: «Сез кайда булдыгыз?»- дип сорый. Балалар: «өйдә», «урманда», «бакчада» һ.б. дип җавап бирәләр. Бабай: «Сез анда нишләдегез?»-ди. Балалар бергәләп бертөрле хәрәкәт белән нәрсә эшләгәннәрен күрсәтәләр. Бабай белергә тиеш. Дөрес җавап әйтелгәч, балалар йөгерәләр, бабай аларны куа. Беренче тотылган бала бабай була.